**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Чирмешән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**21 ноябрь 2024 ел** **№ 6**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Казанка
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 14 октябреннән 31 октябренә кадәр киләсе мәсьәлә буенча этаплап үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде: «2025 елда Чирмешән авыл җирлегенең Казанка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугышчы-интернационалистларның тол хатыннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә яшәүче гражданнардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрүгә ризамы:

- **коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Казанка торак пунктындагы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту, дератизация чараларына түләү, корыган агачларны һәм куакларны кисү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Казанка торак пунктындагы гомуми белем бирү учреждениеләренең урам яктыртуларын монтажлау, демонтажлау, ремонтлау, алмаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Казанка торак пунктындагы чишмәләр территорияләренең

санитария-яклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Казанка торак пунктында урамнарны карап тоту, үлән чабу, ботакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар сатып алу, тракторны тоту, аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен материаллар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, арба һәм махсус техника сатып алу, кирәкле запас частьләр сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 134 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 76 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 75 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Казанка торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча карарны: «2025 елда Чирмешән авыл җирлегенең Казанка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугышчы-интернационалистларның тол хатыннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә яшәүче гражданнардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрүгә ризамы:

**- коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Казанка торак пунктындагы зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту, дератизация чараларына түләү, корыган агачларны һәм куакларны кисү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Казанка торак пунктындагы гомуми белем бирү учреждениеләренең урам яктыртуларын монтажлау, демонтажлау, ремонтлау, алмаштыру, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** (Чирмешән торак пунктындагы, Казанка торак пунктындагы, Түбән Чегодай торак пунктындагы чишмәләр территорияләренең санитария-яклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, Чирмешән торак пунктындагы, Казанка торак пунктындагы, Түбән Чегодай торак пунктындагы, Кече Чегодай торак пунктындагы урамнарны карап тоту, үлән чабу, ботакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарларын җыю, триммерлар сатып алу, тракторны тоту, аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары, тракторчыга хезмәт хакы түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен материаллар, ягулык-майлау материаллары сатып алу, арба һәм махсус техника сатып алу, кирәкле запас частьләр сатып алу).

3. Мәгълүмати стендларда гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә: Чирмешән авылы, М.Титов ур., 7 йорт Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Р.С.Хәлиуллин